КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

БОЕРЫК ПРИКАЗ

2023нче елның 28 августы, №158-п

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары белән расланган Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе нигезендә БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымта итеп бирелгән административ регламентын расларга.

2. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте

күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2021 елның 10 февралендәге 8-п номерлы;

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2021 елның 10 февралендәге 8-п номерлы боерыгы белән расланган Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 15 ноябрендәге 165-п номерлы;

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.С. Сәлимгәрәев

«Татмедиа» республика
матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр
агентлыгының
2023 елның “ ” __________
№__________

боерыгы белән расланды

**Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Агентлык) тарафыннан социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтүнең тәртибен һәм стандартын билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр – «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 22 пунктының 1 пунктчасында билгеләнгән Татарстан Республикасы территориясендә түбәндәге иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтә торган социаль юнәлешле коммерцияле булмаган (алга таба – социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар, коммерцияле булмаган оешмалар) оешмалар:

1) нәшерлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

2) телепрограммалар эшләү һәм тарату;

3) радиопрограммалар эшләү һәм тарату.

1.3. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә профильләштерү (дәүләт хезмәтен мөрәҗәгать итүченең Агентлык үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә ачыкланган таләпләренә туры килә торган вариант нигезендә күрсәтү) үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәтенең исеме

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр (алга таба – бәяләмә) бирү

2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүне тәэмин итүче – массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге (алга таба – Бүлек).

Дәүләт хезмәте Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – күпфункцияле үзәк) аша күрсәтелми.

2.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүче коммерцияле булмаган оешмалар реестры турында» 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешманы иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручы итеп тану турында карар кабул итү кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча бәяләмә;

2) бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә (әлеге Регламентка 2 нче кушымта).

Бәяләмә һәм бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә Агентлык бланкасында рәсмиләштерелә.

Реестр язмасы дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып тормый.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе Татарстан Республикасының нинди дә булса дәүләт мәгълүмат системасында теркәлми.

2.3.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә үзе сайлаган ысул белән бирелә (җибәрелә):

язма рәвештә мөрәҗәгать итүченең үзенә тапшырыла яисә почта аша юллана;

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә, электрон почта адресы буенча яисә Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал) мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына (техник мөмкинлекләр булганда), яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы) шәхси кабинетына вазыйфаи затның квалификацияле көчәйтелгән электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

2.3.3. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтүнең нәтиҗәсен кәгазьдә –электрон документның нөсхәсе рәвешендә алырга хокуклы.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә алу өчен мөрәҗәгать итүче Агентлыкка мөрәҗәгать итә.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы

2.4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан почта аша җибәрелгән яисә шәхсән

тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте Агентлык тарафыннан гариза һәм документлар теркәлгән көннән алып 30 көн эчендә күрсәтелә.

2.4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда яисә Республика порталында шәхси кабинет аша бирелгән очракта, Агентлык тарафыннан дәүләт хезмәте гаризага Бердәм порталда яисә Республика порталында эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм «Документларны тикшерү» статусы (техник мөмкинлекләр булган очракта шәхси кабинетта чагыла) бирелгән көннән алып 30 көн эчендә күрсәтелә.

Кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә Агентлык мөрәҗәгатьләр җибәргән очракта, күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, әмма ул 30 көннән дә артмаска тиеш.

Агентлык әлеге карарны кабул итү срогын озайту турында Агентлыкка гариза кергән көннән алып 30 көн эчендә мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә.

2.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең хокукый нигезләре

Агентлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда) һәм Республика порталында түбәндәгеләр урнаштырыла:

дәүләт хезмәтен күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәтен күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтен күрсәтүче Агентлык, Агентлыкның вазыйфаи заты, дәүләт граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль рәвештә тапшыра торган кирәкле документлар исемлеге:

а) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза):

билгеләнгән формадагы кәгазь документ рәвешендә (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);

Бердәм портал яисә Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, әлеге Регламентның 2.6.4 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон рәвештә (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләр кертү юлы белән тутырыла);

б) гамәлгә кую документларының күчермәләре;

в) мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен раслый торган документ (Агентлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта тапшырыла). Бердәм портал яисә Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, шәхесне таныклый торган документтагы белешмәләр Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада (алга таба – ЕСИА) исәпкә куюны раслаганда тикшерелә.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтнең иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына (белешмәләр, характеристикалар, эксперт бәяләмәләре, республика башкарма хакимият органнары каршындагы иҗтимагый советлар бәяләмәләре һәм башкалар) туры килүен нигезләүче документлар кушып бирелергә мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче тиешле иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү буенча социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән очракта, мөрәҗәгать итүче күрсәтә торган хезмәтләрнең иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына туры килүен нигезләүче өстәмә документлар тапшыру таләп ителми.

2.6.3. Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкасы мөрәҗәгать итүчегә Агентлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә бирелә. Гариза бланкасының электрон формасы Агентлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

2.6.4. Гариза һәм кушып бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан, ышанычнамә нигезендә) тапшырылырга йә кәгазьдә, салынган документлар саналып, почта аша җибәрелергә мөмкин. Почта элемтәсе ярдәмендә җибәргәндә, гариза һәм кушып бирелә торган документлар билгеләнгән тәртиптә таныклана.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан (63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендә) Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) яисә Республика порталы ярдәмендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Бердәм портал яки Республика порталы аша җибәрелгәндә, гариза мөрәҗәгать итүченең гади электрон имзасы белән имзалана.

Гади электрон имза алу өчен мөрәҗәгать итүчегә ЕСИАда теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарт дәрәҗәдән дә түбән булмаган исәп язуын расларга кирәк.

Гаризага кушып бирелә торган электрон документлар (документларның электрон рәвешләре), шул исәптән ышанычнамәләр, pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматларындагы файллар рәвешендә җибәрелә, .

Тапшырыла торган электрон документларның (документларның электрон рәвешләре) сыйфаты документ текстын тулысынча уку һәм документ реквизитларын тану мөмкинлеге бирергә тиеш.

2.6.5. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында түбәндәге белешмәләр алына:

социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешманың «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә төзелгән контрактларны үтәү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында булмавын раслый торган белешмә (Монополиягә каршы федераль хезмәт идарәсе);

мөрәҗәгать итүче документларны тапшырган айның беренче числосына социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрында мөрәҗәгать итүче турында язма булу хакында белешмә (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы).

Мөрәҗәгать итүче әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләр булган документларны шул исәптән, мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә тапшырырга хокуклы.

Күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы аңа хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигез була алмый.

Әгәр иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләү Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирүне оештыру турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә кушымтадагы исемлек буенча берничә республика башкарма хакимияте органы (алга таба – кызыксынучы органнар) тарафыннан башкарылса, сыйфатның туры килүе турында бәяләмә үзенә гариза кергән кызыксынучы орган тарафыннан бирелә. Сыйфатның туры килүе турында бәяләмә бирү турында гариза кергән кызыксынучы орган, кирәк булганда, башка кызыксынучы органнардан, шулай ук дәүләт хакимиятенең башка органнарыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә белешмәләр соратып ала.

2.7. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны тулысынча тапшырмау;

кәгазьдә тапшырылган документларда мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга, текстны укырга һәм (яисә) документ реквизитларын белергә мөмкинлек бирми торган кимчелекләр булу;

63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләре нигезендә гади электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) гариза һәм документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру (гаризаны электрон формада биргәндә).

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар дәүләт хезмәтен күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда яисә Республика порталында, Агентлыкның рәсми сайтында булган мәгълүмат нигезендә тапшырылса, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.8. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законнарда каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

а) иҗтимагый файдалы хезмәтнең Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә (күрсәтелә торган хезмәтнең күләме, сроклары, сыйфаты) туры килмәве;

б) иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүдә турыдан-туры катнашкан затларның (шул исәптән граждан-хокук шартнамәләре буенча җәлеп ителгән оешмалар һәм хезмәткәрләр) кирәкле квалификациясе (шул исәптән һөнәри белем, тиешле өлкәдә эш тәҗрибәсе) булмау, квалификацияле затлар саны җитмәү;

в) бәяләмә бирү елы алдыннан булган ике ел эчендә оешманың иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүенә бәйле рәвештә булган гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, компетенцияләре буенча башка дәүләт органнары тарафыннан нигезле дип табылган шикаятьләр булу;

г) оешма турындагы мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем файдаланырлык булу дәрәҗәсенең Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә (алар булса) туры килмәве;

д) бәяләмә бирү елы алдыннан булган ике ел эчендә 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кабул ителгән килешүләрне үтәү кысаларында хезмәт күрсәтүләр нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында оешма турында мәгълүмат булу;

е) дөрес булмаган белешмәләр булган документлар яисә тиешенчә рәсмиләштерелмәгән документлар тапшыру.

2.8.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза Бердәм порталда яисә Республика порталында, Агентлыкның рәсми сайтында бастырылган дәүләт хезмәтен күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гарызнамә биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гарызнамә биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артык түгел.

Аерым категория мөрәҗәгать итүчеләр өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасын теркәү вакыты

2.11.1. Агентлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза һәм документлар кергән көнне теркәлә. Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада алынган гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә теркәлә.

2.11.2. Гаризаны Бердәм портал яки Республика порталы аша җибәргәндә мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Бердәм порталда (техник мөмкинлек

булган очракта) яисә Республика порталында шәхси кабинетта һәм электрон почта аша гаризаның теркәлү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелгән хәбәрнамә ала.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документлар тутыру өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедий мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

2.12.2. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлардан (алга таба – объект) файдалану өчен законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә түбәндәге шартлар тудырыла:

1) бинага тоткарлыксыз керү һәм аннан чыгу мөмкинлеге;

2) хезмәт күрсәтү урынына керү максатларында бина буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шул исәптән объект хезмәткәрләре ярдәмендә;

3) транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып;

4) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләре нык бозылган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

5) инвалидларның күрсәтелә торган хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалануын тәэмин итү өчен, аларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешенчә урнаштыру;

6) “Эзтабар этне махсус өйрәтүне раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында” Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән рәвештә һәм тәртиптә бирелгән документы булганда, мөрәҗәгать итүчене бинага ярдәмче эте белән бергә кертү;

7) хезмәт күрсәтүләрдән башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә файдаланырга комачаулык итүче каршылыкларны узуда инвалидларга хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан ярдәм күрсәтү.

2.12.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектлардан һәм дәүләт хезмәтен күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.13. Дәүләт хезмәтеннән һәркемнең файдалана алу мөмкинлеге һәм аның сыйфат күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтеннән һәркемнең файдалана алу мөмкинлеге күрсәткечләре:

кабул итү үткәрелә торган, документлар тапшырыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;

мәгълүмат стендларында, Агентлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда) һәм Республика порталында дәүләт хезмәтен күрсәтү алымнары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар керә алырлык булуы;

дәүләт хезмәтен күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга биналарның инвалидлар өчен уңайлылыгына бәйле булмаган, аларга хезмәтләрне башкалар белән тигез дәрәҗәдә алырга комачаулый торган башка киртәләрне үтүдә булышлык итү;

гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге;

гариза һәм документлар Республика порталында шәхси кабинет аша электрон рәвештә бирелгәндә, хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда) һәм Республика порталында электрон документлар рәвешендә алу мөмкинлеге.

2.13.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

1) документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;

2) дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен бирү срогын үтәү;

3) Агентлык белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;

4) мөрәҗәгать итүченең Бүлек белгечләре белән үзара хезмәттәшлеге саны:

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар биргәндә һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

Мөрәҗәгать итүче белән бер хезмәттәшлекнең дәвамы – 15 минуттан артык түгел.

Мөрәҗәгать итүче, Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) яисә Республика порталыннан файдаланып, радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә хокуклы.

2.13.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүматны мөрәҗәгать итүче Агентлыкта, Бердәм порталдагы (техник мөмкинлек булганда) һәм Республика порталындагы шәхси кабинетта алырга мөмкин.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында белешмәләр, хезмәт күрсәтү тәртибе һәм башка документлар белән танышу мөмкинлеге Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда) яисә Татарстан Республикасы порталында мөрәҗәгать итүченең алдан авторизация узуыннан башка башкарыла.

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында «Шәхси кабинет»та авторизация узгач (техник мөмкинлек булганда), мөрәҗәгать итүче түбәндәге мөмкинлекләргә ия була:

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза бирү;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның (график файлларның) электрон рәвешләрен беркетү;

дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында белешмәләр алу;

дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алу.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларны электрон формада бирү мөмкинлеген тәэмин итү өчен мөрәҗәгать итүченең гади электрон имза ачкычы булырга тиеш. Гади электрон имза ачкычын алу өчен мөрәҗәгать итүчегә ЕСИАда теркәлү процедурасын узарга кирәк. ЕСИАда алдан теркәлүнең онлайн-формасы "Интернет" челтәрендә сайтта урнаштырылган (“Интернет” челтәрендәге сайтның исеме – esia.gosuslugi.ru/).

ЕСИАда (физик зат буларак) теркәлү процедурасын үткәннән соң мөрәҗәгать итүче-физик зат, гади электрон имза кулланып, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Порталында авторизация узарга тиеш. Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда), Татарстан Республикасы Порталында «Шәхси кабинет»та авторизация узганнан соң, мөрәҗәгать итүче элек бирелгән гаризаларны һәм хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә карый ала.

2.14. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәктә дәүләт хезмәтен күрсәтү үзенчәлекләрен һәм электрон рәвештә дәүләт хезмәтен күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр;

Дәүләт хезмәте турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә белешмәләр бирү хакында таләпләр.

2.14.1 Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Консультация мөрәҗәгать итүче Агентлыкка шәхсән үзе, телефон һәм (яисә) электрон почта, почта аша мөрәҗәгать иткәндә бирелергә мөмкин.

2.14.3. Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәктә  күрсәтелми.

2.14.4. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәткәндә, мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

б) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон рәвешләре 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге 7.2 пункты нигезендә Бердәм порталны (техник мөмкинлек булганда) яисә Республика порталын файдаланып таныкланган документларны һәм мәгълүматны тапшырырга;

в) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында электрон рәвештә бирелгән гаризаларның үтәлеше турында белешмәләр алырга;

г) дәүләт хезмәтен күрсәтү сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә алырга;

е) дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан кабул ителгән карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) һәм (яисә) Республика

порталы ярдәмендә Агентлык карарына һәм шулай ук аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауга) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда) яисә Республика порталында, өстәмә рәвештә нинди дә булса гариза бирү зарурлыгыннан башка, электрон форманы тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.14.5. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә «Ведомствоара бердәм электрон хезмәттәшлек системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.14.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.14.7. Дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы гарызнамә составында күрсәтелми.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вариантларының исемлеге, ул шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре буенча бирелгән документларда һәм төзелгән реестр язмаларында җибәрелгән хаталарны төзәтү өчен кирәкле дәүләт хезмәте күрсәтү вариантларын үз эченә ала.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре буенча бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны төзәтү бердәй вариантта гамәлгә ашырыла һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сроклары, мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре, түләү күләме һәм тәртибе, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган документлар һәм юридик әһәмиятле гамәлләре белән аерылучы аерым сценарийлар юк.

3.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре буенча бирелгән документның дубликатын бирү вариантлары исемлеге, шул исәптән мондый дубликатны бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре буенча документның дубликаты бирелми.

3.3. Мөрәҗәгать итүчене профильләштерүнең административ процедурасын тасвирлау

Мөрәҗәгать итүчене профильләштерү процедурасы гамәлгә ашырылмый.

3.4. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү һәм ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара гарызнамәләр төзү һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтүнең нәтиҗәсен әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүнең нәтиҗәсен бирү (җибәрү);

6) техник хаталарны төзәтү.

3.5. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә

Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон аша һәм (яисә) почта (шул исәптән электрон) аша, шулай ук Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) яисә Республика порталы аша дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен Бүлеккә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен алу турында һәм башка мәсьәләләр буенча консультация бирә. Кирәк булганда, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә ярдәм итә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны тутыру өлешендә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультация, тапшырылган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча искәрмәләр, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

3.6. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.6.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы зат аша гомуми бүлеккә, почта, электрон почта аша, Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) яисә Республика порталы аша гариза бирә ала.

Гариза заказлы хат белән почта аша җибәрелергә мөмкин.

Электрон рәвештә җибәрелә торган гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә имзалана (таныклана) һәм гомуми файдаланудагы электрон чыганаклардан һәм (яисә) мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән, "Интернет" челтәрен дә кертеп, файдаланып тапшырыла.

Заказлы хат белән почта аша яисә электрон рәвештә тапшырылган гариза гомуми тәртиптә карала.

3.6.1.1. Бүлек белгече тапшырылган документларның тулылыгы әлеге Регламентның 2.6 пункты таләпләренә туры килүен тикшерә.

3.6.1.2. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы зат аша мөрәҗәгать иткәндә, әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту өчен нигезләр булуы турында хәбәр итә һәм аңа баш тартуның сәбәпләрен аңлатып, документларны кире кайтара. Баш тарту таләп буенча язма рәвештә рәсмиләштерелә.

Гаризаны һәм документларны почта (электрон почта) аша җибәргәндә, Бүлек белгече баш тартуның сәбәпләрен язма рәвештә аңлатып, тапшырылган документларны почта (электрон почта) аша кире кайтара.

3.6.1.3. Гомуми бүлек белгече документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, гариза һәм документларны Агентлыкта документлар белән эшләү инструкциясендә билгеләнгән тәртиптә терки һәм карау өчен Бүлеккә тапшыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы электрон гариза электрон почта яисә Интернет аша Бүлеккә җибәрелә.

Әлеге Регламентның 3.6.1.1-3.6.1.3.3 пунктларында билгеләнгән процедуралар гариза һәм документлар Агентлыкка кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза һәм документлар.

3.6.2. Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) һәм Республика порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза һәм документлар кабул итү

3.6.2.1. Гаризаны электрон рәвештә тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

авторизация уза;

электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон гаризага документларны яисә документларның электрон рәвешләрен беркетә (кирәк булганда);

дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга куя);

хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслый (электрон гаризада тиешле тамга куя);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гаризада тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.6.4 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаны җибәрү турында хәбәрнамә ала.

Тутырылган гарнизаны формаль-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә Агентлык билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче электрон гаризаны тутыру процессында гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан электрон рәвештәге гаризаның дөрес тутырылмаган юллары ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүчегә хатаның характеры һәм аны төзәтү тәртибе турында турыдан-туры гаризаның электрон формасында хәбәр ителә.

Әлеге пункта билгеләнгән административ процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларның үтәлү нәтиҗәсе булып Агентлыкка электрон хезмәттәшлек системасы аша җибәрелгән электрон эш тора.

3.7. Ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

3.7.1. Мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 2.6.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Бүлек белгече дәүләт хезмәтен

күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) әлеге Регламентның 2.6.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлеге нигезендә түбәндәге белешмәләрне алу өчен ведомствоара гарызнамә җибәрә:

социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешманың 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэмин итүчеләр реестрына кертелмәвен раслый торган белешмә (Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе);

мөрәҗәгать итүче документларны тапшырган айның беренче числосына социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрында мөрәҗәгать итүче турында язма булу хакында белешмә (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы).

Ведомствоара мәгълүмати гарызнамә күрсәтелгән органнарга мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү максаты белән җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар шушы Регламентның 3.6 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң өч көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тиешле органнарга җибәрелгән гарызнамәләр.

3.7.2. Ведомствоара гарызнамәләр буенча әлеге Регламентның 2.6.5 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яисә аларда булган белешмәләр) аларның электрон рәвешләре саклана торган дәүләт органнары тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектлары башкарма дәүләт хакимияте органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруның тәкъдим ителә торган кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә тиешле ведомствоара гарызнамә юлланган вакыттан 48 сәгатьтән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Агентлыкка бәяләмә бирү турында гариза килгән очракта, Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә таянып, иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләү берничә республика башкарма хакимият органы, шул исәптән Агентлык тарафыннан гамәлгә ашырыла, бәяләмә Агентлыкка бирелә. Агентлык кирәк булганда башка кызыксынган органнардан, шулай ук дәүләт хакимиятенең башка органнарыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә белешмәләр соратып ала. Ведомствоара гарызнамәгә җавап бирү срогы

күрсәтелгән органнарга шундый мөрәҗәгать кергән көннән алып 15 эш көненнән артык була алмый.

Белешмәләрне файдалануның максаты булып мөрәҗәгать итүче тапшырган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук закон бозуларны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозуны булдырмый торган карарлар кабул итү тора.

3.8. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен әзерләү.

3.8.1. Бүлек белгече түбәндәгеләрне тикшерә:

документларны рәсмиләштерүнең дөреслеген (тапшырылган документларның форма һәм эчтәлек буенча законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килүен, документларда барлык кирәкле имзаларның, мөһерләрнең, реквизитларның булуын тикшерү, ассызыклауларның, төзәтмәләрнең юклыгын тикшерү);

бәяләнелә торган хезмәтләрнең аның эчтәлегенә булган таләпләргә туры килүен (тапшыру күләме, сроклары, сыйфаты);

иҗтимагый файдалы хезмәт башкаруда турыдан-туры катнашкан затларның (шул исәптән оешма хезмәткәрләренең һәм граждан-хокук шартнамәсе нигезендә җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән һөнәри белеме, тиешле өлкәдә эш тәҗрибәсе) булуны, кирәкле квалификациясе булган затлар саны җитәрлек булуны;

44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында оешма турында гариза бирелгәнгә кадәр ике ел дәвамында мәгълүмат булмауны;

бәяләмә бирү турында гариза бирелгәнгә кадәр ике ел дәвамында оешманың иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүенә бәйле гамәлләренә (гамәл кылмауга) һәм (яисә) карарларына суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, компетенцияләренә бәйле рәвештә башка дәүләт органнары тарафыннан нигезле дип танылган шикаятьләр булмауны;

оешма турында мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә (алар булганда) туры килүне;

Кагыйдәләргә 2 нче кушымта нигезендә хат һәм бәяләмә проектын, яки, әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән очракларда, бәяләмә бирүдән баш тарту турында әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән рәвештә дәлилләнгән хәбәрнамә проектын әзерли;

документларның әзерләнгән проектларын килештерү өчен бүлек башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар ведомствоара гарызнамәләргә җаваплар алган көннән алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: килештерү өчен бүлек башлыгына җибәрелгән хат, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектлары.

3.8.2. Бүлек башлыгы хат, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектларын тикшерә һәм килештерү өчен аларны җитәкченең беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура бу проектлар Бүлек башлыгына килештерүгә кергән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен җитәкченең беренче урынбасарына җибәрелгән хат, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектлары.

3.8.3. Җитәкченең беренче урынбасары хат, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектларын килештерә һәм аларны җитәкчегә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура бу проектлар килештерү өчен кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм җитәкчегә карауга җибәрелгән хат, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектлары.

3.8.4. Җитәкче хат белән бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилле хәбәрнамәне имзалый һәм аларны Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар бу Регламентның 3.8.3 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән алып ике эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җитәкче кул куйган хат, бәяләмә йә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә.

3.9. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (җибәрү)

3.9.1. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, гаризада күрсәтелгән элемтә чарасыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе хакында хәбәр итә.

Процедураны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура җитәкче хатны имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләрне мәгълүмат системаларында урнаштыру, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәтен күрсәтүнең нәтиҗәсе, һәм бу нәтиҗәне алу ысуллары хакында хәбәр итү.

3.9.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) тәртибе

3.9.2.1. Мөрәҗәгать итүче Агентлыкка дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен сорап мөрәҗәгать иткән очракта Бүлек белгече бәяләмәне, бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул (шәхсән, почта, электрон почта, факс) белән бирә (җибәрә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура түбәндәге очракларда башкарыла:

гаризада бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне тапшыру ысулы буларак почта (электрон почта, факс

буенча) күрсәтелгән очракта – бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә;

гаризада бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне тапшыру ысулы буларак шәхсән килеп алу күрсәтелгән очракта – мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелгән (җибәрелгән) бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилле хәбәрнамә.

3.9.2.2. Мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен сорап Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) яисә Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, аның шәхси кабинетына дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон рәвеше җибәрелә, ул Агентлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар дәүләт хезмәтен күрсәтүне (дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуны)раслый торган документ имзаланган көнне Агетлыкның вазыйфаи заты тарафыннан башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) яисә Республика порталы аша мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүне (шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документ җибәрү (тапшыру) тора.

3.10. Техник хаталарны төзәтү

3.10.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Бүлеккә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында ирекле формада төзелгән гариза (тәкъдим ителә торган форма әлеге Регламентка 3 нче кушымтада китерелә);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ;

техник хата булуны дәлилли торган юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә киткән техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкиле) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яисә Бердәм портал аша (техник мөмкинлек булганда), яисә Республика порталы аша тапшырыла.

3.10.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, кушып бирелгән документлар белән гаризаны терки.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза һәм документлар Агентлыкка кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада алынган гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә теркәлә.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлек белгеченә карауга юнәлдерелгән документлар һәм гариза.

3.10.3. Бүлек белгече бәяләмәне йә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне яңадан рәсмиләштерү максатларында:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны һәм аңа кушып бирелгән документларны карый;

хат, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә йә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектларын әзерли;

әзерләнгән документларны имза кую өчен җитәкчегә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар бу Регламентның 3.10.2 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә йә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә белән җитәкчегә җибәрелгән хат.

3.10.4. Җитәкче үзгәртелгән бәяләмә йә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә теркәлгән хатны имзалый һәм аларны Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар шушы Регламентның 3.10.3 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән алып бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә йә бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле хәбәрнамә кушып бирелгән җитәкче кул куйган хат.

3.10.5. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне яңадан рәсмиләштерү турында, техник хатаны төзәтү турындагы гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар җитәкче хатны имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне яңадан рәсмиләштерү турында хәбәр итү.

3.10.6. Бүлек белгече үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәне йә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне техник хатаны төзәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (шәхсән, почта буенча, электрон адреска, факс аша) тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура түбәндәге очракларда башкарыла:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризада үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәне йә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне тапшыру ысулы буларак почта элемтәсе (электрон адрес, факс буенча) күрсәтелгән очракта – рәсмиләштерелгән бәяләмәне йә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлиләнгән хәбәрнамәне рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә ;

техник хатаны төзәтү турындагы гаризада үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәне йә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне шәхсән алу күрсәтелгәндә – мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелгән (җибәрелгән) үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә йә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә.

## 4. Административ регламентның үтәлешен тикшереп тору

4.1. Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларның җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан үтәлешен һәм башкарылуын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне тикшереп тору тәртибе

4.1.1. Әлеге Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларның Агентлыкның җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан үтәлешен һәм башкарылуын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне тикшереп тору тиешле административ процедураның үтәлеше өчен җаваплы зат, Бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.1.2. Агымдагы тикшереп тору әлеге Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларның Агентлыкның җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан үтәлешен һәм башкарылуын тикшерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә башкарыла.

4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп торуның тәртибе һәм рәвешләре, планлы һәм планнан тыш тикшерүләр тәртибе һәм чиратлылыгы

4.2.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору тикшерүләр уздыруны, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозуларны ачыклауны һәм бетерүне, мөрәҗәгать итүчеләрнең Агентлыкның вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрен карауны, карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формасы булып тикшерүләр үткәрү тора:

эш башкаруны алып бару, шул исәптән документларны кабул итү срокларын һәм тәртибен үтәү;

документларны карау нәтиҗәләренең закон таләпләренә (әлеге Регламентка) туры килүе;

дәүләт хезмәтен күрсәтү срокларын, тәртибен үтәү.

Тикшерүләр уздыруның ешлыгы планлы (эш планнары нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) характерда була.

4.2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) элек ачыкланган әлеге Регламент таләпләрен бозуларны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны бозуларны бетерүне тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) юридик затлар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Агентлык вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган орган вазыйфаи затларының дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында үзләре кабул итә (башкара) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен җаваплылыгы

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы булган гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне тикшереп тору (шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан) тәртибенә һәм рәвешләренә таләпләрне характерлаучы нигезләмәләр

Дәүләт хезмәтен күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә Агентлык эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 11 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылынмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр Агентлыкның, аның дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затының, дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр Агентлыкка шикаять белдерү хокукына ия.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә җитәкче кабул иткән карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырыла.

5.2. Мөрәҗәгать итүче шулай ук түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гарызнамәне, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән гарызнамәне теркәү срогы бозылу;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтүнең билгеләнгән срогы бозылу;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документларны яки мәгълүмат бирүне яисә гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуның нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралмаган булса, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Агентлыкның, Агентлыкның вазыйфаи затының, дәүләт граждан хезмәткәренең үзләре җибәргән хаталарны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны төзәтүдән баш тартуы йә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогы яисә тәртибе бозылу;

9) туктатып тору нигезләре федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

10) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүне беренче тапкыр кире какканда аларның булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Агентлыкның, Бердәм порталның, Республика порталының рәсми сайтыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

Шикаять кергән көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

5.4. Шикаять теркәлгән көненнән алып 15 эш көне эчендә каралырга тиеш. Агентлык, Агентлыкның вазыйфаи заты яки дәүләт граждан хезмәткәре мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән йә җибәрелгән хаталарны төзәтүдән баш тарткан очракта, яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылганда шикаять бирелгән очракта, шикаять теркәлгән көненнән алып биш эш көне эчендә карала.

5.5. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган Агентлыкның, Агентлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең исеме, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Агентлыкның, Агентлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең дәгъвалана торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүченең Агентлыкның, Агентлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең карары һәм гамәл кылуы (гамәл кылмавы) белән килешмәвенә дәлилләр.

5.6. Гариза бирүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны төзәтү рәвешендә, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган акчаларны мөрәҗәгать итүчегә кире кайтару рәвешендә канәгатьләндерелә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм аның теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, ачыкланган хокук бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба башкарырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип табылган очракта, гариза бирүчегә юллана торган җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат китерелә.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яисә нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яисә җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

(тәкъдим ителә торган форма)

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе

________________________________________
фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

________________________________________
оешманың исеме

________________________________________
адресы (почта һәм (яисә) электрон)

________________________________________
телефон номеры (булган очракта)

ГАРИЗА

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма

____________________________________________________________________________
(социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма исеме)

тарафыннан күрсәтелә торган

____________________________________________________________________________
(иҗтимагый файдалы хезмәт атамасы)

иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларына туры килүе турында бәяләмә бирүне сорыйм.

Оешма чит ил агенты функциясен үтәүче коммерцияле булмаган оешма булып саналмый, һәм бер елдан артыграк вакыт дәвамында иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтә, алар иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләүнең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иҗтимагый файдалы хезмәтләре исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларын раслау турында»2016 елның 27 октябрендәге 1096 номерлы карары белән расланган критерийларга туры килә:

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________
(иҗтимагый файдалы хезмәтнең Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән аның эчтәлегенә карата таләпләргә туры килүен раслау (бирү күләме, сроклары, сыйфаты);

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәт башкаруда турыдан-туры катнашкан затларның (шул исәптән граждан-хокук характерындагы килешүләр буенча җәлеп ителгән оешма һәм хезмәткәрләр) кирәкле квалификациясе (шул исәптән һөнәри белем бирү, тиешле өлкәдә эш тәҗрибәсе) булуын, шундый затларның саны җитәрлек булуын раслау)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның аларны күрсәтү сыйфатыннан канәгать булуын раслау (суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, башка органнар тарафыннан бәяләмә бирүгә кадәрге 2 ел эчендә үз компетенцияләре нигезендә оешманың иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле гамәлләренә (гамәл кылмауына) һәм (яисә) карарларына шикаять булмау)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(коммерцияле булмаган оешма турында мәгълүматның ачыклыгын һәм һәркем файдалана алырлык булуын раслау)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында оешманың булмавын раслау)

Раслау документлары теркәлә:

1. ______________________________
2. ______________________________
3. ______________________________

______________________________________________________________________

Вазыйфасы

"____"____________20_ел
М. у. (булганда)

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

(тәкъдим ителә торган форма)

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма тарафыннан
күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатының
билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарту
турында дәлилләнгән хәбәрнамә

"Татмедиа" матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләү нәтиҗәләре буенча ______________________________________________________
(социаль юнәлешле коммерцияле оешманың тулы исеме һәм төп дәүләт теркәү номеры)

____________________________________________________________________________

түбәндәге иҗтимагый файдалы хезмәтләренә
____________________________________________________________________________.
(иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең атамасы)

социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарта.

Күрсәтелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына түбәндәге нигезләрдә туры килми:

____________________________________________________________________________.
(критерийларга туры килмәү күрсәтелә)

Җитәкче
имза  фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта)

"____"____________20_ел
М. у. (булганда)

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

(тәкъдим ителә торган форма)

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе

______________________________________
фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

______________________________________
оешманың исеме

______________________________________
адресы (почта һәм (яисә) электрон)

______________________________________
телефон номеры (булган очракта)

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә биргәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

______________________________________________________________
(бирелгән документ)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:_____________________________________________________

______________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

Документның әзерлеге турында мине хәбәр итүегезне сорыйм

______________________________________________________________________

(хәбәр итү ысулы)

_________________ ___________________________________ ______________________

(дата) (гариза бирүче/вәкил имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына

кушымта (белешмә)

Реквизитлар
«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү һәм аны күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы вазыйфаи затлары

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы

| Вазыйфасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Җитәкче | (843) 570-31-22 | ra.tatmedia@tatar.ru |
| Җитәкче урынбасары | (843) 570-31-02 | Id.Mirgalimov@tatar.ru |
| Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү идарәсе башлыгы | (843) 570-31-12 | A.Bakunina@tatar.ru |
| Массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге баш белгече | (843) 570-31-12 | Lil.Gallyamova@tatar.ru |
| Гомуми бүлек башлыгы | (843) 570-31-23 | Tatyana.Kazachenko@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Адресы | Вазыйфасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|---|
| 420014. Казан ш., Ирек мәйданы, 1 й. | Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы | (843) 264-76-19 | Lyaysan.Nizamova@tatar.ru |